وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُواْ

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+


# Дин вә Мәгыйшәт

№13 (208). 18 октябрь 2013/13-зөлхиҗҗә-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ


## БЕРДӘМ БУЛСАК, БӘРӘКӘТ ТӘ КИЛЕР

**Корбан гаете гыйбадәтенә җыелган халык белән республика мәчетләре быел да шыгрым тулы иде. Колшәриф мәчетендә барган бәйрәм вәгазен һәм намазын, гадәттәгечә, турыдан-туры трансляция аша барлык милләттәшләребез дә карый алды. Кеше бик күп иде: намаз уку залларына, балконнарга гына сыймыйча, халык мәчет каршындагы мәйданны да тутырды.**



Корбан гаетен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин алып барды. Ул иң элек Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез мактауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерде. Безне бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырга өйрәткән, безнең өчен иң күркәм үрнәк булган Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде), аның гаилә әһелләренә, барлык сәхабәләренә сәламнәребезне һәм салаватларыбызны җиткерде. Корбан гаете белән котлады.

Мөфти хәзрәтләре: "Мөкатдәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып, барчабызга да Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә ирешергә насыйп булсын", - дип, мөселманнарны Россия Президенты Владимир Путин, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның бәйрәм котлаулары белән дә таныштырды.

Корбан гаетенең килеп чыгу тарихына тукталып, Камил хәзрәт әлеге бәйрәмнең асылында Аллаһы Тәгаләгә якынаерга теләк ятуын билгеләп үтте. Камил хәзрәт Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгеллеген, аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешүе турында сөйләде. Кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен генә чалып, гаиләсен, туганнарын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне сыйлап, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһның ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Мөфти шул ук вакытта Аллаһның рәхмәтенә ирешү өчен, Корбан гаете көнне генә түгел, һәрдаим тырышлык күрсәтергә, начар гамәлләрдән тыелып яшәргә чакырды. "Ибраһим (г. с.) һәм аның улы Ис-

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

## Әбу Мансур әл-Мәтуриди – хак юл имамы

**Имам Әбу Мансур әл-Мәтуридиның гакыйдә һәм фикыһы Әбу Хәнифә гакыйдә һәм фикыһына нигезләнгән.**

Әбу Хәнифә фикыһта мәзһәбкә нигез салучы, бу мәзһәб аның исеме белән атала, ә Әбу Мансур әл-Мәтуриди гакыйдәдә мәзһәбкә нигез сала, бу мәзһәб мәтуридия дип атала башлый.

Фикыһта хәнәфи мәзһәбен тоткан кешеләрнең күпчелегенең гакыйдәдә һәм аның ысулында мәтуридия мәзһәбен тотуы билгеле. Безнең көннәрдә ислам дөньясының яртысы хәнәфи-мәтуриди мәзһәбен тота.

Имам Мәтуриди дүртенче дәрәҗәдә (Әһле-Тәһриҗ) һәм хәнәфи мәзһәбенең өченче дәрәҗәсендә (табака) тора. Ул белемнәрен Әбу Бәкер Әхмәд ибне Исхак әл-Җүрҗани, Нүсәйр ибне Яхъя әл-Бәлхи, Нишапурда казый булган Әбу Бәкер Мөхәммәд ибне Әхмәд әл-Җүрҗани кебек, Мөхәммәд ибне Хәсән Әш-Шәйбани шәкерте булган Сөләйман әл-Җүрҗани шәкертләреннән ала. Ә Мөхәммәд ибне Хәсән Әш-Шәйбани, үз чиратында, Әбу Хәнифәнең танылган шәкертләренең берсе. Аның шәкертләре арасында фикыһ һәм кәлямдә танылган, Әбу Әхмәд әл-Ияды, Әбел-Хәсән ибне Сәид әл-Рустуфуни, Әбу Мөхәммәд Габдел-Кәрим ибне Муса әл-Паздави һ. б. кебек галимнәр була.

Имам Мәтуридиның барлык фикерләре дә Коръәни-Кәримгә һәм Сөннәткә нигезләнә. Имам өстәл янында гына утыручы галим булмый. Меңнәрчә замандашлары аның вәгазьләрен тыңлагач туры юлга баса. Халык алдында чыгыш ясау мөмкинлеген ул беркайчан да ычкындырмый. Яхшы хәтер, зур гыйлеме булган тел остасы һәрвакыт диспутларда җиңеп чыга. Имам мөгътәзиләләрнең ялгыш фикерләрен урнаштырырга тырышкан Мәэмүн хәлифеннән соң (197/81 нче еллар) яши һәм хезмәт итә.

Шул ук вакытта гарәп теленә тәрҗемә ителгән борынгы грек фәлсәфәчеләре хезмәтләре тарала. Кайбер галимнәр, аларның хезмәтләре белән мавыгып китеп, ялгыш фикерләрен тарата башлый. Имам Мәтуриди, әл-Әшгари һәм аларның шәкертләренең гыйльми хезмәтләре шул заман мөселманнарына Аллаһы Тәгалә илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам) күрсәтеп калдырган дөрес юлны сайларга булыша. Имам Әгъзам Әбу Хәнифәнең дин нигезләре буенча фикерләрен аның хезмәтләреннән имам Мәтуриди аерып чыгара. Ул бу гыйлемне системалаштыра, фактлар белән тулыландыра. Киләчәк буын Әбу Хәнифә мәзһәбе имамнары дин гыйлеме буенча имам Мәтуриди иҗтиһады буенча эш йөртә һәм бу белем безнең көннәргә кадәр үзгәрмичә килеп җитә.

Шулай итеп, Гыйльмел-Кәлям буенча сөнниләрнең гыйльми хезмәтләре бары тик Коръәни-Кәримгә һәм Сөннәткә нигезләнә. Имам Әбу Мансур әл-Мәтуриди күп кенә китаплар авторы, ләкин безнең ике китабын билгеләп үтәсе килә:

1. «Китабүт-Тәүхид».
2. «Тәгъүиләтел-Куръән» (тафсир, автор аятьләрне башка аятьләр белән аңлата). Без бу ике китапны бөтен яктан да бик мөһим дип исәплибез: аларда бирелгән гыйлемнәре буенча да, күләмнәре буенча да.

Мәкаләнең ахырында ислам дөньясында, бигрәк тә Әһле Сөннә вәл Җәмәгатьтә Әбу Мансур әл-Мәтуриди һәм Әбел-Хәсән әл-Әшгаринең керткән өлешләре гаять зур булуын ассызыклап үтәсе килә, чөнки алар ялгыш фикерләрне дөресләреннән аера белгән. Алга таба Урта Азиядә, Идел буе Болгар дәүләтендә, Пакьстанда, Һиндстанда, Әфганстанда, - Госманлы империясенең күпчелек өлешендә яшәүче хәнәфиләр үзләрен имам Әбу Мансур әл-Мәтуридига, ә шәфигыйлар, мәликиләр, хәнбәлиләр үзләрен имам Әбел-Хәсән әл-Әшгарига охшата. «Мәтуридия-Әшгария» гакыйдәсе – Әһле Сөннә вәл Җәмәгатьнең бердәнбер дөрес гакыйдәсе.

Ысул нигезләрендә алар арасында, кайбер фикерләр буенча 13 терминнан кала (ихтиләф ләфзи), бернинди дә каршылыклар юк.

Алга таба без, иншә Аллаһ, имам Әбу Мансур әл-Мәтуриди тоткан Әһле Сөннә вәл Җәмәгать гакыйдәсен карарбыз.


*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*


### ЯҢАЛЫКЛАР

#### Кылган хаҗлары кабул булсын

**Быел Татарстан мөселманнарына 1200 кешелек квота бирелгән булса, хаҗ сәфәренә ике ай кала инде бер урын да калмаган иде.** Хаҗилар билгеләп үткәнчә, "ДУМ РТ ХАДЖ" программасы җитәкчесе Хәбибулла Нәфисуллин Татарстан мөселманнарының хаҗ сәфәрен бик югары дәрәҗәдә оештырган. Тәҗрибәле, кайгыртучан төркем җитәкчеләре, хаҗ йолаларын үтәү һәм башка шәригать кануннары буенча уздырылган дәресләр, вәгазьләр, көненә ике тапкыр туклану, хаҗиларны әл-Хәрәм мәчетенә транспортта йөртү, табибларның хаҗилар сәламәтлеген һәрдаим кайгыртып торуы - быелгы хаҗ сәфәрен алдагы елларда башка операторлар оештырганнарыннан әнә шулар аерып тора да инде.

Быелгы хаҗ сәфәрендә катнашучы Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев та Татарстан хаҗ операторының эшеннән канәгать булуын белдерде. Татастан мөфтие Камил Сәмигуллин шәригать мәсьәләләрендә эксперт буларак һәм хаҗиларга вәгазьләр сөйләү өчен Илдус хәзрәт Фәизне махсус җибәргән иде. Аның Гарәфә тавы итәгендә басып торганда кылган догасыннан хаҗиларның күзләре яшьләнгән.

Тиздән хаҗиларның беренче төркеме Казанда булачак.

#### "Игелекләре меңе белән кайтсын"

**Азнакай районы Түбән Якый авылында яңа мәчет ачылды.** "Кыска вакыт эчендә, ел ярым дигәндә, җирле үзидарә органнары, депутатлар һәм халыкның уртак көче белән бире дә мәчет бинасы калкып чыкты. Эшләгән игелекләре аларга меңе белән кайтсын", - дип теләде муниципаль район башлыгы Марсель Шәйдуллин һәм ул имам-хатыйб Сәхипҗан Шакировка истәлекле бүләк - алтын төсендәге җепләр белән Коръән аятьләре чигелгән зур шәмаил тапшырды. Авыл халкы озак вакыт мәчетсез яшәгән булган. Яңа гыйбадәтханә исә авылның үзәгендә зур булмаган бер калкулыкта урнашкан.

Шушы ук районның Актүбә бистәсендә мәдрәсә ачылу тантанасы да булды. Әлеге бина, ике ай эчендә ремонт ясалып, мәдрәсә булып сафка басты.

#### Татар яшьләре бәйрәм итте

**16 нчы октябрь көнне "Казан" милли мәдәният үзәгендә татар яшьләре Корбан ашы үткәрде.** Чараны Бөтендөнья татар яшьләре форумы, "Ихлас" мөселман яшьләре хәрәкәте, Татарстан Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге оештырды. Корбан ашында дини һәм дөньяви уку йортларында укучылар, татар яшьләре арасында танылган егет-кызлар - барлыгы өч йөзләп кеше катнашты.

## "Ярдәм кебек мәчетне күргән юк иде"

**Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Корбан гаете уңаеннан Казанның Ярдәм мәчетендә бәйрәм вәгазен тыңлады һәм намаз укыды. Президентны Ярдәм мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов Сукырларны һәм начар күрүчеләрне тернәкләндерү үзәге белән таныштырды. Президент Илдар Баязитовка: "Дөньяда Ярдәм кебек үзенчәлекле мәчет күргәнем юк иде әле", - дип белдерде.**

Рөстәм Миңнехановка сукыр һәм начар күрүче кешеләр өйрәнү өчен ясалган юл билгеләрен, шулай ук юл һәм идән япмаларын аерырга ярдәм итә торган тротуар плитәләрен күрсәттеләр. Шуннан Татарстан Президенты күрү буенча инвалидлар өчен Тернәкләндерү үзәгенең кабинетларын һәм уку сыйныфларын карап чыкты.

Ярдәм мәчетендәге күрү буенча инвалидлар өчен Укыту-тернәкләндерү үзәге 2013 нче елның июлендә ачылды. Әлеге комплекста мәчет, чит шәһәрләрдән килүчеләр өчен тулай торак, ашханә, уку сыйныфлары, китапханә, мини-типография бар. Монда сукырлар һәм начар күрүчеләр Луи Брайль системасы буенча язарга, укырга, шулай ук компьютерда эшләргә, төрле һөнәрләргә һәм белгечлекләргә өйрәнә, урында адаптация курсларын уза.

Бәйрәм намазында шулай ук Казан мэры Илсур Метшин, Мәскәү районы башлыгы Дамир Фәттахов һәм башка җитәкчеләр катнашты.





# ГЫЙЛЕМ ЧЫЛБЫРЫ ӨЗЕЛМӘДЕ



**Шушы көннәрдә Россия ислам институтында дүртенче мәртәбә Саматов укулары узды. Анда Идел-Урал төбәге мөселманнарының рухый мирасы хакында фикер алышынды, анализланды.**

Әлеге чара Коръән уку белән башланды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның беренче урынбасары Рөстәм Батыр котлау сүзе белән чыкты һәм Ханты-Манси - Югра автономияле округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматовка "Рухый мирас" бүләген тапшырды. Төбәгебездә генә түгел, бөтен Россиядә һәм чит илләрдә дә мәгълүм галим, казый, халык мәхәббәтен яулаган хәзрәт, мәңге исебездән чыкмас шәхес Габделхак хәзрәт Саматов хакында күпләр, бик күпләр сөйләде. Беркайчан да өзелмәс рухый нәсел, илаһият чылбырының корыч бөгәрҗәләре барланды. Хакыйкый исламны саклаучы һәм башкаларга тапшыручы хәзрәт хакында җылы һәм кадерләү сүзләре яңгырады. "Әтибез үрнәк кеше иде, тәкъвалык дәрәҗәсендә иде. Мирасны өйрәнү мөһим", - диде Сургут каласында 20 ел хезмәт күрсәтүче Таһир хәзрәт Саматов. ТР Президенты Аппаратының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы Илнур Гатауллин һәм Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшинның чыгышлары да котлау һәм илаһияттә мирасны саклау - яшьләрне алдагы мөһим эшләргә чакыру булып яңгырады. Россия ислам институты, "Мөхәммәдия", Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә, Казан ислам колледжы шәкертләре дә моны тыңладылар.

"Бүген дә мирасыбызны дәвам итүчеләребез булу Габделхак хәзрәтнең эшчәнлеге җимеше ул", - диде Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин. - Габделхак хәзрәт Саматов хакында шәкертләребезгә ел әйләнәсе сөйлибез, май ае башында каберенә дә барабыз".

Габделхак хәзрәтнең икенче улы Хәлил хәзрәт Саматов Ханты-Мансийск шәһәренең имам-мөхтәсибе. Әтисенең шәкертләре күп булуын искә төшерде ул. Гыйлем алу зур тырышлык соравын да ассызыклады. "Гыйлем ул - тәкъвалык, гыйлем - Аллаһы Тәгаләдән курку җимеше, гыйлем - иман җимеше, акыл зиннәте. Кеше исән вакытта аны мактамагыз, дия иде әти. Имамнар абруен төшермәсәк иде, дип тә әйтә иде", - дип, Хәлил хәзрәт хатирәләре белән дә уртаклашты.

Галим Илдус Заһидуллин мөселманнарның үткәндәге хокукый статусы хакында бәян итте, бүген үтә кирәкле мәсьәлә. Журналист Василә Рәхимованың чыгышында татар хатын-кызларының дин юлындагы эшчәнлекләре бәян ителде. Бусы да милләтебезне олылаучы күркәм бер күрсәткеч булды. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе проректоры Зөлфәт Габдуллинның чыгышы "Буыннар бәйләнеше" дигән теманы ачуга юнәлтелгән иде. Остазның әһәмияте хакында әйтте ул: "Гыйлем чылбыры өзелмәде", - диде.

Әйе, торгынлык елларында, дин әфьюн ул, дигән вакытларда сүнми-сүрелми торган, нык иманлы Габделхак хәзрәт Саматов булу, аны күрү татар күңеленә горурлык һәм яшәү мәгънәсе уятты. Зөлфәт хәзрәт бу хакта да саллы итеп тыңлаучылар күңеленә җиткерде.

**Әлмира ҺӘДИЯ,**
**җәмәгать эшлеклесе**



# ЯШЬЛӘР МИРАСНЫ БЕЛЕРГӘ ТИЕШ



**"Саматов укуларының быелгысының үзенчәлеге нидә булды?" - дигән сорауны без аны оештыручыларның берсе - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең фән һәм уку-укыту бүлеге баш белгече Айдар КАРИБУЛЛИНга юлладык:**

- Быел без шәкертләрне күбрәк җәлеп итәргә тырыштык. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге һәм "Мөхәммәдия" мәдрәсәләреннән, Россия ислам институтыннан байтак шәкертләр катнашты анда. Ни өчен яшьләр, дисезме? Үзем дә яшь буын вәкиле буларак әйтәм, хәзерге яшьләр совет чорында динебезне саклап калучылар турында, гомумән, ул чорның бөтен фаҗигасен белеп бетерми әле. Менә әкренләп шәкертләр арасыннан шушы юнәлештә фәнни-тикшеренү эшләре алып баручылар чыга башлады.

Минем үземә беренче тапкыр 2011 нче елда Саматов укуларының икенчесен оештыруда катнашу насыйп булды. Ул эшне Вәлиулла хәзрәт Якупов башлап йөргән иде. Соңгыларын менә аннан башка гына үткәрдек. Ни кызганыч, шәхесләр китә, алар белән бергә тулы бер чор китә. Габделхак хәзрәтне күреп белгән, аралашып яшәгән кешеләр, дин әһеленең өлгесе иде, дип сөйлиләр. Безнең буынга аны күреп калу насыйп булмады. Ләкин аның укучылары, танышбелешләре белән еш аралашып торабыз. Хәзер төп бурычыбыз - шушындый хәзрәтләребезнең мирасын барлау, элеккерәк чорда ислам диненең торышын, милләтебез тарихын өйрәнү һәм аны киң катламга чыгару. Шәхсән үземнең Габделхак Саматов хезмәтләре белән танышуым Россия ислам институтының магистратурасында укыган чагымда булды. Махсус курсларда без Россиякүләм исламны үстерүдә һәм таратуда зур өлеш керткән яңа чор дин әһелләренең эшчәнлеген өйрәнеп, алар күтәргән проблемаларны анализлый идек. Шул вакытта укытучым миңа ике авторның - Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб һәм Габделхак хәзрәт Саматовларның китапларын укып чыгарга кушты. Баш казый чагында хәзрәт үзе нинди хөкемнәр биргән - шулар хакында тәфсилле, мавыктыргыч, аңлаешлы итеп язылган "Шәригать" өчтомлыгын мин бик тиз укып чыктым. Аннары аның "Милләтебездә ислам дине" дигән китабын да кулдан-кулга йөрттек. Хәзрәт үзе тарихчы булмаса да, халкыбызга ислам дине ничек кергән, Россия империясендә, совет чорында ислам нинди халәттә булган - тарихый мизгелләрне кызыклы итеп тасвирлаган. Тарихта үзләреннән соң җуелмас эз калдырган мөфтиләребез турында да кыйммәтле мәгълүмат җиткергән.

**- Саматов укуларының алдагыларын ничек уздыру турында да фикерләр бөреләнгәндер инде...**

- Алдагы елларда аны чорларга бүлеп, аерым секцияләрдә уздырырга кирәктер, бәлки. Аннары инде Россия күләменә чыгарга да вакыт җиткәндер, дип уйлыйбыз.

**Мәрьямбану ХАФИЗ**

# МӘРҖАНИЛЕ ХАЛЫКТАН БЕЗ

*(Уйланулар)*

2013 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА МӘРҖАНИ ЕЛЫ

**Олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән йортлы урамнан атлыйм. Бик күп еллар инде ул урамнан Мәрҗани мәчетенә намазга йөрибез. Мәрҗани мәчете төзекләндерелгәннән соң, икенче катындагы зур мәһабәт залында без "Мөслимә" иҗтимагый оешмасының Мөхлисә Буби исемендәге Зыялылар клубы әгъзалары бик күп чаралар, очрашу-күрешүләр, кичәләр уздырабыз. Аллага шөкер! Минем бу урамнан йөрүемә дә байтак еллар инде. Буыннар алышынды, мәчеткә йөрүче бабайлар, әбиләр алышынды, яшәрде. Өзелмәс бер корыч җеп булып, буыннар дәвам итә.**

Мәрҗани мәчете, Мәрҗани йорты! Болар хәзер дә, гасырлар буена да татар халкының йөзек кашыдай кадерле вә зиннәтле булыр, иншә Аллаһ! Боларны Мәрҗани исеменнән аерып карап булмый.

Әйе, быел Универсиада алдыннан, Каюм Насыйри урамы танымаслык булып үзгәртелде. Урам юлларын бүген танырлык та түгел. И-и-и, уйлый китсәң, дыңгыр-дыңгыр трамвай йөрде бит әле бу урамнан. Ул узган саен мәчет нигезе дерелди иде. Шунлыктан безнең мөселман хатын-кызларының да мәчеткә ярдәмебез булды. Без дә, мәхәллә кешеләре дә бу хакта республика җитәкчеләренә мөрәҗәгать иттек, Мөселман хатын-кызлары берлеге исеменнән -  махсус үтенечебезне дә яздык. Нәтиҗәдә, трамвай юлы алынды, трамвайлар дыңгырдаудан, мәчет нигезе дә дәрелдәүдән туктады. Аллага шөкер!

Мәрҗани яшәгән йорт төзекләнделде, элеккеге кыяфәте кайтты. Ул йорт яныннан узган саен йөрәгебез әрни иде. Йә тәрәзә рамы каерылган, йә рамдагы пыялалар коелган. Боларны күргән саен җитәкчелеккә үтенечләр белән чыктык, әмма җаваплары ышанычлы булмады. Ул йорт Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Мәдәният министрлыгы, музей карамагында булуын да хәбәр иттеләр. Язып та чыктык, зәңгәр экраннар аша да фикеребезне җиткердек. Берсендә капка астыннан үрмәләп кереп, бүлмәләрен карап чыгыйм әле дип, икенче катка менә торган баскычтан күтәрелмәкче идем, такталары сүсәргән, сыгыла һәм шытырдый башлады, аска карадым, баз шәйләнә. Төшеп китсәм, кемнең сөяге череп ятуын да белмәсләр, дип кире чыктым...

Мәрҗани йорты булган урам - хәзер танымаслык. Татарстан урамыннан керүгә, бер могҗизаи урынга эләккәндәй хис итәсең үзеңне. Хыялымда мин галим белән бергә атлыйм кебек. Әнә, уң якта, яңа сәхифәне ачкандай, ышанычлы куллар Казан сурәтен тотып тора, могҗиза арты могҗиза дигәндәй, иске алачык урынына яңалары төзекләндерелгән. Урам диварларында гаҗәеп биек баганаларда фонарьлар яна. Арырак китүгә сулда тарихый Мәрҗани колледжы урнашкан. Арырак колледжның яңа бинасы балкый, рәттән үк остазларның һәм шәкертләрнең яшәү тулай торагы сафка баскан. Боларны Мәрҗани үзе күрсәме, бөтен мөритләрен, шәкертләрен, хәзрәтләрне җыеп, моңарчы яшәп киткәннәр рухына догасын юллар иде. Ә каршыда Мәрҗани паркы, гаҗәеп, тарихы шулай ук сине җитәкләп үткәннәргә алып китә. Бик кадерле, кадерле дә соң бу урыннар, әнә, Мәрҗани мәчете! Ишегалды мәйданына аяк басабыз. Тагын да мәгърурланган. Арырак, җәмәгать, Апанай мәчете. Үзе бер хозурлык!

Бу хакта да аерып язарбыз әле. Ә бүгенге сүзебез Мәрҗани хакында.

…Шиһабетдин Мәрҗани хәзерге Әтнә районына керә торган Ябынчы авылының указлы мулласы гаиләсендә туган. Башлангыч белемне әтисенең Ташкичү мәдрәсәсендә ала. Аннары ун ел дәвамында Бохараның Күкелташ, Мир-Араб, Сәмәркандның Ширдар мәдрәсәләрендә укый. Ул елларда Мәрҗани ислам дөньясы корифейларының хезмәтләре белән таныша. Аның фикерләве планетар югарылыкта, киң масштаблы тирәнлектә алып барыла. Гарәп һәм фарсы телләренең нечкәлекләрен өйрәнә, фәлсәфә, тарих фәннәре асылын белүне үз итә. Математика, геометрия, астрономия белән шөгыльләнә, дөньякүләм мәшһүр галимнәрнең мирасын өйрәнә. Җиребез куенындагы руда катламнарыннан "энҗемәрҗәннәр"не эзли һәм таба. Гомере буе аларны халкына аңлатып, бүләк итү белән мәшгуль була. Казанга кайткач, беренче мәчетнең имамы һәм мәдрәсәнең мөдәррисе була.

Мәрҗанине дөньяның бик күп галимнәре белгән. Ул алар белән аралашкан, әңгәмәләшкән. Танылган рус галиме, академик Василий Бартольд аны: "Татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучы…" - дип атаган. "Шиһабетдин Баһаветдин углы Мәрҗанинең китабы энтография һәм тарих материалларына байлыгы ягыннан рус теленә генә түгел, Европадагы башка телләргә дә тәрҗемә ителергә лаек", - дип яза Казан университеты профессоры, галим Н.Ф. Катанов. Галимнең хезмәтенә татар әдибе Галимҗан Ибраһимов та зур бәя бирә: "…Милли тарихыбызның нигезе", - ди.

Ә татар халык шагыйре Габдулла Тукай болай дип яза:

Чыкты ахры бездән дә бер бөтен кеше,  
Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше,  
Татарда да гыйрфан уты кабынганны  
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.

Кирәк булса, әйтеп бирим: ул шәп хәзрәт,  
Тулган ай күк балкып чыккан  
Шиһап хәзрәт,  
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,  
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.




Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм,  
Шәрафәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм;  
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне  
Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм.

…Галимнәр язуынча, Мәрҗани - тарихчы, дини реформатор, этнограф, археограф, көнчыгыш белгече, педагог. Аның һәрьяклы мәгърифәтлелеге, энциклопедик белеме галимне дөньякүләм остазлар дәрәҗәсенә күтәрә. Аның хезмәтләре - олы мирас. Ул руханый офык даирәсен киңәйтеп, гафләт-гамьсезлектән, ваемсызлыктан котылырга, милли, әхлакый аңга, дини мәгълүматка ия булып, бергәлеккә, бердәмлеккә чакырды. Галим милли мирасның дөньякүләм мирастан аерылгысызлыгын аңлатты. Менә шундый җәүһәри мирас, хәзинә калдырган галим Шиһабетдин Мәрҗанинең олуглыгын, аның халкыбыз, динебез һәм киләчәгебезнең өметле, акыллы булуы өчен тырышуын яшьләргә тапшырырга тиешбез.

Безнең әле, Мәрҗани йорты Казанның дини һәм әхлакый тәрбия, мәгърифәтчелек үзәге булса иде, дигән теләк-максатыбыз да бар. Мәрҗани укулары да узар, аның музее яшь галимнәрне тәрбияләү үзәге дә булыр, анда дини укулар, ачык дәресләр, очрашулар да узар, иншә Аллаһ. Галимнең музеенда үзе яшәгәндәгечә урындыклар, өстәл, этажерка, тәсбихләр, энциклопедияләр, китаплары булыр дип уйлыйбыз.

Аның акыл хәзинәсенең кадерен белсәк иде. Быелны гына түгел, бу елларыбызны мин Мәрҗани унъеллыгы дип атар идем. Әйе, Мәрҗани елы кысаларында галимнең бөеклеге байтак ачылды. Әмма, әле җитәрлек түгел. Минем аны өйрәнү җәһәтеннән Мәрҗани оныкларының иң нәниләре өчен дә бәйгеярыш, конкурс оештырасым килә. Яшьләребезнең бәхетен Мәрҗани хәзрәтләре калдырган мирасны ныклап өйрәнүдә күрәм мин.

**P.S.** *Ш.Мәрҗанинең үзе тарафыннан безгә бүгенге көндә үтә дә мөһим мәсьәлә күтәрелгән булган. "Мәрҗани һәрнәрсәдә мөселманлык вә татарлыкны күрергә сөйдегеннән (сөйгәнлегеннән), һәрнәрсәнең милли булуына әһәмият бирә икән. Мәсәлән, берәр эшне башкалардан эшләтергә ту(г)ры килсә яки берәр нәрсә мөселман кибетләрендә табылмаса: "Моны мөселман эшләргә ярамыймы икән? Ул нәрсәне мөселман сатарга ярамыймы икән?" - диеп, күп вакыт әйтә; бигрәк тә ашамлык, кондитер нәрсәләрен мөселманнар пешермәвенә бик тәэссеф итә (көенә) икән. Кибетләргә өелеп куелган ләүхәләр (вывескаларга) мөселманча язылмаса яки мөселманча түбән генә язылса, эче поша: "Ник мөселманча язмыйсыз? Хөкүмәт тарафыннан манигъ (тыючы) булмадыктан (булмастан) соңра мөселманча язарга һәм мөселманчаны түбән-кечкенә генә түгел, ачык итеп өскә язып куерга кирәк", - дип әйтә икән. Ислам тарихына әһәмият бирдекеннән (бирүе сәбәпле), исемнәр ахырына "-ов/-ев, -ин" тоташтыруны мәкрүһ (килешсез, сөйкемсез) күрдегеннән (күрүе сәбәпле), "Гомеремдә Бәһаветинов диеп кул куйганым юк. Тарих миляди истигъмаль иткәнем (христиан ел исәбен кулланганым) вә язганым юк" дип әйтә икән. Китапларында да һичкемнең фамилиясен "-ов/-ев, -ин" кушымчасы илә язмый вә һәр вакыйганы һиҗри тарих илә язадыр" (Мәрҗани. - II том. - Б. 168-169).*

*Мин бу юлларны сезнең игътибарга тәкъдим итмичә, соңгы ноктаны куярга җөрьәт итмәдем.*

*Халкыбызның үзенең тирән катламнарыннан күтәрелгән шәхес - Мәрҗаниле халыктан вә токымнан без.*

***Әлмира ҺӘДИЯ,  
"Мөслимә" газетының баш мөхәррире, "Халкыбызга хезмәте өчен" медале иясе, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре***

# БӘЙРӘМ БУЛСА – ШУНДЫЙ БУЛСЫН...

**Безнең күпләребез Корбан бәйрәмен сарык суеп, аш үткәрү дип кенә белә. Ә менә гарәп илләрендә, Төркиядә Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре зурлап үткәрелә. Соңгы елларда Казаныбызда да бу бәйрәмнәргә караш үзгәрә башлады. Чыннан да, аларны гаилә бәйрәме дәрәҗәсенә күтәрү Аллаһ каршысында күркәм гамәл булыр иде. Алай гына да түгел, балаларда кечкенәдән әлеге бәйрәмнәргә мәхәббәт уяныр иде.**

Уку йортыбызда - РИИда егетләр төркеменең бәйрәм каникуллары сорап гариза язуларын белгәч, без дә алардан калышмаска булдык. Чаллыда укучы дус кызым инде күптәннән кунакка дәшә иде, тәвәккәлләдем дә кузгалдым. Чаллыга мин кичкырын гына килеп төштем. Бәйрәмгә әзерлек шарларны кабартып, бүлмәне бизәүдән башланды.

Иртәгесен иртәнге намазны укыгач, көнебезне татарларның күркәм гореф-гадәтеннән башладык - дустым белән коймак пешердек. Шундый тәмле килеп чыкты! Кызлар белән бер-беребезгә бүләкләр бирештек. Озакламый кунаклар да килә башлады. Кунаклар дигәнебез әниләренә ияреп килгән кечкенә балалар инде. Резедә исемле мөселман кардәшебез алар өчен төрле уеннар оештырды, Әминәбез Ибраһим пәйгамбәр турында, Корбан бәйрәменең килеп чыгу тарихын сөйләде. Балаларның үзләренә дә сораулар биреп, аларның бу бәйрәм турындагы белемнәрен тикшердек. Ярышларда дөрес җавап биргәннәренә бүләкләр дә биреп бардык. Рәсем ясау бәйгесендә, пәйгамбәрләрне санаганда балаларга әниләре дә ярдәмгә килде. Вакыт сизелми дә үтеп китте. Ахырдан бергәләшеп алып килгән күчтәнәчләр белән сыйландык. Әниләр дә балаларына бүләкләр әзерләгәннәр икән, аларны да тапшырдык. Балаларга бу бәйрәм бик ошады, йөзләрендә шатлык нурлары биеште! Әле мондый бәйрәмдә үземнең дә беренче тапкыр гына булуым. Сабыйларга карап, үзем дә балачакка кайткан кебек булдым. Теләгәндә, әнә ничек итеп тә уздырып була икән бит ул дини бәйрәмнәребезне!

**Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА**

# БЕРДӘМ БУЛСАК, БӘРӘКӘТ ТӘ КИЛЕР

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

мәгыйль (г. с.) кыйссасы безгә тәкъва булырга, ягъни гөнаһлардан, файдасыз гамәлләрдән ерак булып, Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә карата итагатьле булырга өйрәтә", - дип, ул хак мөселманнарга хас булган сыйфатлар турында да сөйләп үтте. "Мөхтәрәм мөселманнар, берберебезне хөрмәт итсәк, кадерләсәк, бердәм булсак, Аллаһы Тәгалә безгә дә бәрәкәт, муллык бирер. Дәүләтебез - матур, киләчәгебез күркәм булыр, яңгырлар да вакытында явар, Аллаһ безгә Үзенең чиксез рәхмәтен ирештерер, төрле афәтләрдән саклар", - дип белдерде мөфти хәзрәтләре.

"Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас күңелдән бары тик файдалы, изге гамәлләр кылырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт тормышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде", - дип, Камил хәзрәт үзенең теләкләрен дә җиткерде.

Аннан соң мөселманнар, тәкъбир әйтеп, гает намазы укыды, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен сорап, дога кылды.

Бәйрәм көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Яңа гасыр" телеканалы белән берлектә "Сөючеләр фида кыла" шигаре астында телемарафон да уздырды. Диния нәзарәтенә гарип ятимнәргә приют ачу өчен Биектау районы Бөреле җирлегендә бина бирелде. Әлеге бинаны төзекләндерү өчен 6 млн сум акча кирәк. Изге ниятне тормышка ашыру максатыннан Татарстан мөселманнары телемарафонга чыкты. Ул иртәнге сәгать биштә "Манзара" тапшыруындагы махсус сәхифәләр белән башланып китте. Телемарафон кысаларында хәзрәтләребез, татар халкының танылган җәмәгать эшлеклеләре, сәнгатькарләре, зыялылар бу изге эшкә үз фикерләрен белдерде; хәйриячелек, дини белем бирү һәм иҗтимагый ислам турында фикер алышты; игелек кылу, республикадагы уку йортларында дин әһелләрен әзерләү, халыкны изгелеккә өндәү, яшьтән балаларны дин юлына бастыру, иҗтимагый исламны пропагандалау һ.б. мәсьәләләр күтәрелде.

Татарстан Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фондыннан хәбәр итүләренчә, кичке сәгать алтыга (18.00) 600 мең сумнан артык акча җыелган. Акча күчерүләр бәйрәмнең соңгы ике көнендә дә дәвам итте. Белми калдым, өлгермәдем, дию-челәр булса, аларга да хафаланмагыз, фида кылырга беркайчан да соң түгел, диясе килә. Приют өчен акча җыю дәвам итә.

**"ЗӘКЯТ" ХӘЙРИЯ ФОНДЫ РЕКВИЗИТЛАРЫ:**
**Наименование сбора "САДАКА".**
**Благотворительный Фонд "Закят".**
**ИНН/КПП 1655068682/165501001**
**ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012**
**р/с № 40703810362190000764**
**(Советское отделение № 6669/015 СБ РФ г. Казани)**
**ОСБ БАНК ТАТАРСТАН № 8610 г. Казани**
**к/с: 30101810600000000603 БИК: 049205603**
**Юридический адрес:**
**420111, г. Казань, ул. Лобачевского, д. 6.**
**Телефон: +7 (843) 225-33-22.**
**Аллаһы Тәгалә үксезләргә күрсәткән ярдәмегезне кабул кылсын.**

## Урта Пошалым мәчетен бергәләп төзик!

Хөрмәтле авылдашлар, якташлар, милләттәшләр һәм дин кардәшләр! Аллаһы Тәгалә кушып, Татарстан Республикасының Арча районы Урта Пошалым авылында мәчет төзелә. Халыкта, ил төкерсә, күл була, диләр. Әйдәгез, шушы саваплы эшне бергәләп башкарыйк! Күгебездә тагын бер изге ай калыксын!

Изге гамәлдә матди ярдәм кылырга теләүчеләр өчен, мәхәлләнең Россия Саклык банкындагы исәп-хисап счёты номеры: 42307810262165010034/ 48.

**Корр. счёты номеры: 20202810167000100679.**

Шулай ук, мәчет төзелешенә акчалата ярдәмне авылда (имам-хатыйбка яисә мәхәллә казначеена) калдырып китәргә дә була.

**Элемтә өчен телефон: 89178689729 (Рәшит Галләм).**

## Ярдәм мәчете ярдәм итәргә әзер

***Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!***

Хөрмәтле шәһәрдәшләребез! Ислам нигезләре курсларында укырга теләгегез булса, сезне Казан шәһәре, Серов урамы, 4а адресы буенча урнашкан Ярдәм мәчетенә бушлай курсларга чакырабыз. Әлеге курслар намаз уку тәртибен, ислам хокукы нигезләрен, әхлак дәресләрен, гарәп алфавитын өйрәнүне һәм тәҗвид кагыйдәләрен үзләштерүне үз эченә ала. Хәзерге вакытта "Яшь мөселман" төркеменә 8-15 яшьлек малайларны җыябыз, дәресләр һәр якшәмбедә көндезге икенче яртыдан (13.30) дүртенче яртыга (15.30) кадәр дәвам итәчәк. Башка яшь төркемнәрендә дәресләр инде башланды. Тулырак мәгълүматны +7 (843) 223-03-86 телефонына шалтыратып белә аласыз.

# ТЕЛ ЭТЛЕГЕН ИТӘ...

**Бәләкәй чакта безне начар сүзләрдән әнкәйләр тыя, соңра психолог та аны начар ди, мулласы да гөнаһ икәнен аңлата, ләкин шуңа да карамастан, күбебез бу тел афәтенә чумган һәм аның чокырыннан чыгарга әле бер дә теләми.**

Хәзер бар җирдә дә сүгенәләр: балалар бакчасына, мәктәпкә карасаң, балалар берберсенә башка сыймаслык сүзләр әйткәләшә, аларның укытучылары һәм тәрбиячеләре дә бик еш кына начар вә нахак сүзләр куллана. Шифаханә яки идарә йорты булсынмы - берсендә дә йомшак иттереп сөйләшмиләр. Кайвакытта минем белән сөйләшеп торганда да, яшь хәзрәт дипме шунда, тугыз катлы итеп сүгенеп куялар.

Шиксез, сүгенү ул - җан чире һәм бу чирне зур тырышлык белән дәваларга кирәк. Беребез дә үпкәләребезгә салкын тисә: "Ярар, үзе төзәлеп, рәтләнеп китәр әле", - дип кул селкемибез бит. Киресенчә, даруханәдән иң кыйммәтле даруларны алып, телефоннарны сүндереп, тиз генә караватка чумабыз. Ә менә кайсыбыз бу тел чиреннән үзен дәваларга ашыга?

Халкыбыз арасында таралган сүгенү яки әдәпсез сүзләр белән сөйләшү хакында төрле фикерләр ишетергә туры килә. Кайсыберләре: "Бу кабахәт гадәткә каршы чыгып булмый, чөнки бу безнең канда", - дип аклана. Икенчеләре: "Мондый кешеләр белән сөйләшмәскә вә сәламләшмәскә", - дип катгый фикер белдерә. Өченчеләре сүгенүне закон нигезендә тыярга чакыра. Сүгенүчеләрнең башларына таяк төшсә, бәлки, туктарлар, янәсе.

Бу турыда барыбызга да уйлап карау лазем, чөнки һәрбер кешенең баласы бар, ул бала шушы сүгенүчеләр арасында яшәячәк, шуңа да һәркем үз нәселенең чиста телле һәм саф күңелле булуын кайгыртып торырга тиеш. Динебез тарафыннан сүгенүнең гөнаһ икәне билгеле, ләкин халкыбыз үзен ничек кенә мөселман итеп күрсәтергә теләмәсен, бу тел этлегеннән әле чистарынырга ашыкмый.



Ислами тормышта сүгенү булырга тиеш түгел, чөнки һәрбер сүгенү - ул кемнедер кимсетү яки кемнеңдер хакын алу булып тора. Ә инде кеше хакына керү, аның дәрәҗәсен төшерү вә мыскыллау безнең диндә тыелган. Рәсүлебез (аңа Аллаһының сәламе вә салаватлары булсын) әйткән: "Кешеләрне сүгү вә дәрәҗәләрен төшерү - яманлык һәм көферлек гамәле" (Мөслим риваяте).

Инде сүгенү сүзләре турында сөйләшеп китик, халкыбыз нәрсә һәм нинди сүзләр белән сүгенә? Ул сүзләр күбрәк кешенең җенси әгъзасын һәм ир белән хатын-кыз арасында була торган җенси мөнәсәбәтне искә алу, һәм шуларга кагылышлы гамәл вә процесслар хакында. Уйлап кына карагыз, акыллы булган кеше сөйләмендә гаурәт урынны һәм кайбер җенси мөнәсәбәтләрне белдергән сүзләрне кулланырмы? Юк, чөнки андый сүзләр һәрбер юньле кешенең дәрәҗәсен төшерә һәм бер үк вакытта аны бик каты мыскыллый. Шул сәбәпле мөселман кешесенең янында торган башка берәүне сүгәргә һәм аның каршында сүгенеп холыксызланып торырга бернинди дә хакы юк.

Татар халкында иң киң таралган һәм иң кабахәт сүгенү - ул үзеңнең яки башка кешенең анасын сүгү. Чөнки шушы шакшы сүзләр артында ниндидер кешенең аналарын зина кылуда гаепләү ята. Бу бит синең каршыңда басып торган кешенең анасы! Ә безнең колакларыбыз гөнаһ сүздән томаланып беткән, шуңа без кайвакытта бу сүзләр үз аналарабыз турында әйтелсә дә, көлеп кенә куябыз!

Ә бит Коръәндә болай әйтелә: "Зинадан пакь булган хатыннарны зиначы дип сүгүчеләр, соңра сүзләрен дөресләр өчен дүрт шаһитны китерә алмасалар - аларга сиксән мәртәбә сугыгыз..." ("Нур" сүрәсе, 4 нче аять).

Кайбер хатыннар һәм ирләр көн дәвамында үзләре дә дистәләгән һәм йөзләгән мәртәбә шушы сүзләрне әйтергә һәм шул рәвешле җәһәннәмдә үзләренә шәп кенә чокыр казырга мөмкин. Ә бит моның хакында Аллаһның Рәсүле безне кисәткән: "Җәһәннәмгә иң күп керүчеләр авызларындагы телләрен һәм ботлары арасында булган әгъзаларын сакламаучылар" (Бохари риваяте).

Телләребезгә ирек биреп кемнедер сөйләвебез, кемнедер сүгүебез - бу тормышта безнең тарафтан кылынган зур хата.

**Хәбир хәзрәт ХАНОВ, Чирмешән мәчете имам-хатыйбы**

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №13 (207) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35422.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 17 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!**